ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОАРЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Школьная ул., дом 30
с.Новый Арыш, 422656

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АРЫШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 30 нчы йорт,
Яңа Арыш авылы, 422656

Тел.: (8-4361) 25-780, , факс: (8-4361) 25-780, эл.адрес: Nars.Rs.@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 26 гыйнвар** **Яңа Арыш авылы** **№ 1**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы8-ФЗ номерлы Федераль законынның 9 маддәснед 3 пункты һәм 12 маддәснед 3 пункты, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында”Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы һәм “Татарстан Республикасы дәүләт комитеты тариф мәсьәләләре буенча” 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карарларына тәнгәллләштереп, КАРАР БИРӘМ

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2023 елның 31гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2024 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Х.С.Зарипов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Яңа Арыш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2024
елның 26 гыйнварындагы 1
номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә**
**2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет куюү) буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,409 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 841,20 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | 8370,20 |

Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 26 гыйнварындагы 2 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2964,70 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2964,70 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 841,20 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1599,60 |
| Җәмгысе: | 8370,20 |